**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның «30» маеннан № 140

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Торакны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану һәм күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2023 елның 27 февралендәге 47 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Торакны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану һәм күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә, торак йортны бакча йорты һәм бакча йортын торак йорт дип тану буенча нигезләмәне раслау турында» 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 27 февралендәге 47 номерлы карары белән расланган торакны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану һәм күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба - Административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Административ регламентның 2.4.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтелә:

теркәлгән көннән алып 30 календарь көн дәвамында, ә гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә зыян күргән һәм шул ук вакытта теркәлгән көннән алып 20 календарь көн дәвамында объектларның (торак урыннарның) җыелма

исемлегенә кертелмәгән объектларның (торак урыннарның) милекчесе, хокук иясе яки торак урынны яллаучының кергән гаризасы яки бәяләнә торган бинаны өстәмә тикшерү үткәрү турында карар (йомгаклау рәвешендә) кабул итеlә; (4 нче кушымта).»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов